РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00


РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 19

2020 елның 21 феврале

«Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Каенлы авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 10 номерлы карары белән расланган «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең график өлешенә үзгәрешләр кертергә: 16:30:021304:11 кадастр номерлы җир кишәрлегендә агросәнәгать комплексы объектларын һәм СХ-1 агросәнәгать комплексы объектларына хезмәт күрсәтү объектларын урнаштыру территориаль зонасын билгеләргә (кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында, Түбән Кама муниципаль районы һәм Каенлы авыл җирлеге рәсми сайтларында бастырып чыгарырга.

3. «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, кертелгән үзгәрешләр белән, Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында (РФ ТП ФДМС) һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.


4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2020 елның 21 февралендәге
19 номерлы карарына
кушымта




Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары

Э.Р.Долотказина